**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА ЛАИШЕВО**

ул. Коммунальная, д.3,
г.Лаишево,422610

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛАЕШ ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Коммунальная ур., 3 нче йорт,
Лаеш ш.,422610

тел: 8-(84378) -2-57-77, факс: 8-(84378) -2-50-62, e-mail:Gorod.La@tatar.ru

**2023елның 09 ноябре** **26 номер**

# КАРАР

**Кадастр номеры 16:24:170121:590 булган җир кишәрлеген шартлы рәвештә файдалануга рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча ачык тыңлаулар билгеләү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 39 статьясына, «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставының 20 статьясына ярашлы рәвештә, Территориянең тотрыклы үсешен тәэмин итү, инженер, транспорт һәм социаль инфраструктураларны үстерү, гражданнар һәм аларның берләшмәләре мәнфәгатьләрен исәпкә алуны тәэмин итү максатларында **карар итәм:**

1.Түбәндәге җир кишәрлегеннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә- - кадастр номеры 16:24:170121:590, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, "Лаеш шәһәре муниципаль берәмлеге", Лаеш шәһәре адресы буенча урнашкан "гомуми файдаланудагы җир кишәрлекләре (территорияләре)нән шартлы рәвештә рөхсәт ителгән "дини файдалану" төренә рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Лаеш шәһәренең җәмәгать тыңлауларын әзерләү комиссиясенә 2023 елның 15 декабрендә 16 сәгать 00 минутта ТР, Лаеш муниципаль районы, Лаеш шәһәре, Коммунал урамы, 3 йорт адресы буенча урнашкан Лаеш шәһәре Башкарма комитеты бинасында җәмәгать тыңлауларын үткәрергә.

3. Ачык тыңлауларга чыгарыла торган мәсьәлә буенча искәрмәләр һәм тәкъдимнәр Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Лаеш шәһәренең халык тыңлауларына әзерлек комиссиясе секретаре тарафыннан түбәндәге адрес буенча кабул ителәдип билгеләргә: ТР, Лаеш районы, Лаеш шәһәре, Коммунал урамы, 3 йорт, тел.: (884378)2-57-77.

4. Әлеге карарны “Кама ягы” («Камская новь») район газетасында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Җитәкче** **В.А. Арефьев**